ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__221_ от «_05__»____03_____2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районында социаль
контракт нигезендә дәүләт социаль
ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне
карау буенча ведомствоара комиссия турында

"Дәүләт социаль ярдәме турында" 1999 елның 17 июлендәге 178 - ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, авыр тормыш хәлендә калган затларга адреслы ярдәм күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Расларга:

-Мамадыш муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составын (1 № лы кушымта);

- Мамадыш муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне (2 № лы кушымта);

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

Татарстан  Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
05.03.2018 ел, 221 нче санлы карарына
1 № лы кушымта

**Мамадыш муниципаль районында  социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия составы**
( килешү буенча)

| | |
|---|---|
| Никитин В.И. | Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе |
| Муллахмәтова М.М. | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге җитәкчесе, комиссия рәисенең урынбасары, |
| Обманова Л.А. | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Мамадыш  муниципаль районы социаль яклау бүлеге консультанты, комиссия сәркатибе |
| Хаҗиев Д.Ф. | Мамадыш үзәк район хастаханәсенең баш табибы, (килешү буенча) |
| Хөснетдинова Л.Р. | Мамадыш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” дәүләт казна оешмасы җитәкчесе |

Татарстан  Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
05.03.2018 ел, 221 нче санлы карарына
2 № лы кушымта

**Мамадыш муниципаль районында  социаль контракт нигезендә**
**дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне**
**карау буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль  районында социаль килешү нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) авыр тормыш хәлендә калган гражданнар мөрәҗәгатьләрен һәрьяклап һәм объектив карау, граждан һәм(яки) аның гаиләсенең авыр тормыш ситуацияләреннән чыгу буенча килешенгән чаралар эшләү максатларында булдырыла һәм коллегиаль орган булып тора.

2.  Ведомствоара комиссия үзенең эшендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актларына, муниципаль районының башка норматив хокукый  актларына, әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Дәүләт социаль ярдәме социаль контракт нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында»  карары белән расланган Тәртип нигезендә күрсәтелә.

4. Ведомствоара комиссияне Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары җитәкли. Ведомствоара комиссия составына Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары, халыкны эш белән тәэмин итү, сәламәтлек саклау, социаль яклау, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү бүлеге һәм башка оешмаларның вәкилләре кертелә.

5. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып тора:

- авыр тормыш хәлендә калган затларга адреслы  социаль ярдәм күрсәтүне оештыру буенча гамәлдәге законнар нигезендә Мамадыш муниципаль районы территориясендә урнашкан  Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары, дәүләт учреждениеләре, җирле үзидарә органнары һәм башка органнарның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүне оештыру;
- граждан һәм (яки) аның гаиләсенең граждан кабул иткән үзара йөкләмәләр нигезендә авыр тормыш ситуацияләреннән чыгу өчен шартлар тудыру.

6. Ведомствоара комиссия хокуклы:

- Ведомствоара комиссия эшендә катнашу өчен вазыйфаи затларны һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең территориаль органнары белгечләрен, җирле үзидарә органнары, оешмаларны һәм вазыйфаи затларны җәлеп итәргә (килешү буенча);
- авыр тормыш хәлендә калган гражданнарны ведомствоара комиссия утырышына чакырырга, аларның аңлатмаларын тыңларга;

- гамәлдәге законнар һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында гражданнарга социаль контрактта һәм үзара йөкләмәләрдә беркетелгән авыр тормыш ситуацияләреннән граждан һәм (яки) гаилә чыгышына юнәлдерелгән чаралар турында фикер алышырга тәкъдим итәргә;
- федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең территориаль органнарына,җирле үзидарә органнарына Мамадыш муниципаль районындагы башка органнарга гражданин һәм (яки) аның гаиләсенең авыр тормыш ситуацияләреннән чыгу буенча үз вәкаләтләре чигендә чараларны тормышка ашырырга тәкъдим итәргә;
- гамәлдәге законнар нигезендә үзара йөкләмәләр турында социаль контрактта беркетелгән шартларның һәм йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүне билгеләргә.

7. Ведомствоара комиссия эшенә җитәкчелек итүне аның рәисе гамәлгә ашыра, Ведомствоара комиссия үткәрүнең вакытын, датасын билгели.

8. Ведомствоара комиссиянең утырышлары зарурлык булганда үткәрелә.

9. Әгәр утырышта ведомствоара комиссия әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, комиссия утырышы вәкаләтле санала.

10. Ведомствоара комиссиянең хокук тәртибен билгеләү өчен һәр утырыш алдыннан комиссия әгъзаларын теркәү үткәрелә.

11. Карар утырышта катнашучы ведомствоара комиссия әгъзалары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта ведомствоара комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.